| СОВЕТ МАЙДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ МӘЙДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 24.09.2018 | № 43-203 |

с. Майдан

Мәйдан авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п. нигезендә Мәйдан авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә, Мәйдан авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 20 нче сентябрендә кабул ителгән 42-199 нчы номерлы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары, Мәйдан авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 нче елның 20 нче сентябрендә кабул ителгән 23 нче номерлы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2018 елның 18 ноябренә Мәйдан авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

"2019 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия һәр авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза булырсызмы?:

- Мәйдан авылы юлларын ремонтлау өчен вак таш сатып алу;
- Тәмте урманчылыгында һәм Ясная Звезда авылында урамнарны яктырту системасын ремонтлау.

ЮК ӘЙЕ".

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В.В.Михеев